**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГӘЙ БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ**

# Эзтабарлар балалар оешмасының эш программасы

Оешма җитәкчесе Д.Ф.Адиятуллина

Эчтәлек


1. Кереш сүз
2. Программаның максаты һәм бурычлары
3. Безнең кагыйдәләр
4. Оешманың традицион чаралары
5. Балалар оешмасының структурасы
6. Укучылар үзидарәсе
7. Программаның юнәлешләре
8. Көтелгән нәтиҗә

Балалык еллары һәр кеше тормышында шәхес буларак үсеш чоры. Бала чакта һәркем файдалы эштә катнашырга, яшьтәшләре белән тиешле дәрәҗәдә аралашырга, коллективта үзен күрсәтергә, танылырга омтыла.

Тәрбия эше бервакытта да җиңел бирелми. Бүгенге көндә бу аеруча актуаль мәсьәлә. Хәзер күпчелек балаларны телевидение һәм урам тәрбияли. Без, педагоглар балаларны тәрбияләүгә барлык көчебезне куярга тиеш. Кызлар һәм малайларның төрле оешмаларга берләшеп, файдалы эшчәнлек алып барулары табигый хәл. Һәр бала үзенчә сәләтле, талантлы. Баланың бирелгән сәләте тулысынча ачылсын өчен акыллы оештыручы кирәк.

Балалар оешмалары - иҗтимагый тормыш мәктәбе ул. Анда катнашу һәм вакытны файдалы, кызыклы итеп үткәрергә, шәхес буларак танылырга ярдәм итә. Үз оешмаларында балалар демократиягә һәм хәбәрдарлыкка, башкаларны инандырырга, кирәкле фикерне тыңлый белергә, активлык күрсәтергә, уңай традицияләрне сакларга, яңаларын барлыкка китерергә өйрәнәләр.

Әлеге программада Зеленодол районы Күгәй башлангыч мәктәбенең балалар оешмасының эшчәнлеге чагыла. Программа 3 елга төзелде. Программаның төп үзенчәлеге: балаларның яшь үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алу. Балаларның кызыклы, файдалы тормыш белән яшәвенә, аларның кечкенәдән инсафлы, әдәпле булып үсүләренә ирешү - төп бурычларның берсе.

Оешмада башкарыла торган эшләр мөстәкыйльлеккә, ирекле аралашуга, сәләтеңне үстерергә өйрәтә. Оешманың үз программасы,  кагыйдәләре бар. Укучылар оешмасы түбәндәге  юнәлешләр буенча  эшли:

- Хезмәт
- Чисталык
- Шәфкатьлелек
- Мәдәният
- Матбугат
- Мәгариф
- Сәламәтлек

***Программаның максаты:***

• оешма эшенә барлык укучыларны да катнаштыру

• оешманың күмәк эшләре аша балаларның әйләнә-тирәне танып белүләренә һәм анда үзләренең урыннарын табуга ирешү

• оешма эшен уеннар оештыруда, плпнлаштыруда мөмкин кадәр күбрәк укучыларны тарту

• балаларның практик осталыкларын арттыру

• балаларның иҗади һәм мөстәкыйл эшләргә өйрәтү

• дөрес ял итәргә, буш вакытларын файдалы үткәрергә ярдәм итү

• уен эшчәнлеге аша балаларның яхшы сыйфатларын , сәләтләрен ачыклау

• үзләренең һәм иптәшләренең уңышларын дөрес бәяләргә, бер-берсенә ярдәм итәргә өйрәтү

Үткәрелә торган чараларга, класстан тыш эшләргә, конкурсларга, ярышларга тартып, баланы аралашучан, үз фикерен кыю әйтә белүче, җәмгятькә файдалы шәхес буларак үстерү.

Безнең максатыбыз - мөмкин кадәр күбрәк укучыны кызыклы тормышка тарту. Укучыларны халкыбызның традицияләрен саклауга, үстерүгә, сәнгатькә тарту, балалар тормышын саклау, матурлык тәрбияләү.

Балалар эзтабарлыкка кабул ителгәннән соң өч баскычка күтәреләләр. Бу баскычларда эш уен формасында группалы һәм индивидуаль алып барыла.

***Безнең кагыйдәләр***

1. Туган илеңнең, үз оешмаңның, үзеңнең исемеңә тугрылыклы булу.

2. Үз халкыңның мирасын, гореф-гадәтләрен, тарихын, йола-бәйрәмнәрен белү.

3. Матурлыкны күрә белү.

4. Туган як табигатен саклау.

5. Үз сәламәтлегең турында кайгырту.

6. Яхшылардан үрнәк алу.

7. Ышанычлы иптәш булу.

8. Биргән сүзеңдә тору.

9. Хезмәтеңне ярату.

10. Үзеңнән кечкенәләргә шәфкатьле булу, олыларны хөрмәт итү, ялгыз әби-бабайларга ярдәм итү.

***Оешманың традицион чаралары:***

- ✓ 1 сентябрь-белем бәйрәме
- ✓ 1 октябрь- өлкәннәр көне
- ✓ 5 октябрь-укытучылар көне
- ✓ Аналар көне
- ✓ Сөмбелә бәйрәме
- ✓ Эзтабарлар бәйрәме
- ✓ Яңа ел
- ✓ Муса Җәлилнең туган көнен билгеләп үтү
- ✓ 21 февраль- Туган тел көне
- ✓ 23 февраль-Ватанны саклаучылар көне
- ✓ 8 март-кызлар бәйрәме
- ✓ 2 апрель - балалар китабы көне
- ✓ 26 апрель – Габдулла Тукай туган көн
- ✓ 9 май-җиңү бәйрәме
- ✓ Соңгы кыңгырау
- ✓ Балалар сабан туе

# Балалар оешмасының структурасы

**“Дуслык” отряды**
**“Елмаю” отряды**

# *Эзтабарлар*

Эзтабарлар сафына 8-10 яше тулган һәм тантаналы вәгъдә биргән укучылар керә.

**ЭЗТАБАР ВӘГЪДӘСЕ**

***Мин(исем, фамилия) әйбәт эзтабар булырга һәм эзтабар кагыйдәләрен тугәл үтәргә сүз бирәм.***

**Безнең девиз:** “*Һәр көнне игелек кыл!”*

**Безнең баскычлар:**

1. Адымнар
2. Башлангыч
3. Сукмаклар

***Эзтабар кагыйдәсе***

Эзтабар-кыю кеше

Эзтабар-намуслы кеше

Эзтабар-кешелекле кеше

Эзтабар-тагын да яхшырак булырга омтыла

**Эзтабарларның атрибуты:** значоклар

**Укучылар үзидарәсе**

*Хокуклары*

- Мәктәпкүләм планлаштырган чараларны үзерләүдә һәм үткәрүдә катнашалар;
- Шимбә һәм ял көннәрендә урамда яки мәдәният йортында 20.00 сәг. кадәр була ала;
- Спектакль яки концерт килгәндә класс белән культпоход оештыра ала;
- Җыелышлар уздырып, мәктәпнең тормышында катнашалар;
- Эзтабарларга укуда һәм тәрбияви чаралар үткәргәндә ярдәм итәләр.

*Бурычлары*

- Фән нигезләрен ныклы һәм тирән үзләштерергә аларны тормышта куллана белергә өйрәнергә;
- Укучыларга куела торган бердәм таләпләрне үтәргә;
- Җәмәгать милкен, мәктәп милкен, табигатьне сакларга;
- Аңлы тәртип булдырырга. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтергә өйрәнергә, җәмәгать урыннарында үз-үзеңне үрнәк тотарга;
- Өлкәннәргә һәм кечеләргә ихтирамлы, игтибарлы булырга.

**Юнәлешләре**

**Хезмәт**

Укуда ярдәм итү һәм файдалы эшләр

**Дөнья**

Әйләнә-тирәне белү һәм аны кайгырту

**Кайгырту**

Шәфкатьлелек, өлкәннәргә һәм кечкенәләргә ярдәм итү, авырулар турында кайгырту

**Гармония**

Спорт, ял һәм күңелле стартлар, кичәләр

## *Көтелгән нәтиҗә*

- укучыларның лидерлыкка омтылышлары арта;
- укучыларда горурлык хисе, Ватанга бирелгәнлек, әхлак кануннарына тугрылык тәрбияләнә;
- укучылар бердәм, дус, тату коллективка туплана, иҗадилыклары арта;
- һәр бала уеннарда катнашып кыюлана төшә, үзендә булган аерым кимчелекләрдән арына бара, иптәшләре арасында бертигез хокуклы кеше буларак, төрле биремнәр үти; балалар үзләренең сәләтләрен, көчләрен кызганмыйлар, уртак нәтиҗә өчен кулланалар;
- татар милли бәйрәмнәрен үткәреп, милли уеннар искә төшә, эстетик зәвык, үз халкы белән горурлык хисе тәрбияләнә.

Сбор темалары

| | |
|---|---|
| Сентябрь | “Отрядта синең тоткан урының” (*Оештыру, вазыйфалар билгеләү*) |
| Октябрь | “Шәфкатьле булу – изге һөнәр” (*ялгыз яшәүче әби-бабайларга шефлык эшен оештыру*) |
| Ноябрь | “Әниләр алтын кебекләр” |
| Декабрь | “Шәфкатьлелек акция”сендә катнашу (*инвалид, ярдәмгә мохтаҗ балаларга булышу*) |
| Январь | “Наркомания-явыз көч” |
| Февраль | “Җыр кешенең юлдашы” |
| Март | “Кошлар – безнең дуслар” |
| Апрель | “Минем бәхетле көнем” |
| Май | “Узебез йомгак ясыйбыз” |